**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 6 май | № 263

г. Казань

Татарстан Республикасы территориясендә файдаланылмый торган хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) юк итү тәртибен раслау турында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары хакында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә файдаланылмый торган хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) юк итү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә Татарстан Республикасы территориясендә файдаланылмый торган хайван каберлекләрен (биотермик чокырларны) юк итү буенча эшләр башкаруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\263.docx